РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.03.2023

№ 41-п

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Кибәче торак пунктында «Татмит Агро» житештерү мәйданчыгының «Восточный» ЖЧЖ дуңгызчылык комплексына килүче автомобиль юлын төзү һәм реконструкцияләү» линия объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә, һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Кибәче торак пунктында «Татмит Агро» житештерү мәйданчыгының «Восточный» ЖЧЖ дуңгызчылык комплексына килүче автомобиль юлын төзү һәм реконструкцияләү» линия объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү турында" 2022 елның 9 сентябрендәге 861-п номерлы карары нигезендә әзерләнгән, халыкның линия объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар аша фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Кибәче торак пунктында «Татмит Агро» житештерү мәйданчыгының «Восточный» ЖЧЖ дуңгызчылык комплексына килүче автомобиль юлын төзү һәм реконструкцияләү» линия объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар билгеләргә. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Ачык тыңлаулар уздыру вакыты - 2023 елның 31 марты, 9:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Кибәче авыл җирлеге, Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урамы, 75 йорт, Олы

Кибәче авыл клубы бинасы.

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров урамы, 52 йорт, 105 бүлмә адресы буенча тапшырылырга мөмкин (эш көннәрендә 8:00дән-16:30га кадәр).

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 2023 елның 31 марты.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

– 2023 елның 1 мартына кадәр әлеге карарны Саба муниципаль районының рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) «Ачык тыңлаулар» бүлегендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау документлары белән бергә бастырып чыгарырга.

– ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне «Интернет» челтәрендә -Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтының «Ачык тыңлаулар» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов